**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дурт-Мунча авыл җирлеге Дурт-Мунча торак пунктында гражданнар җыены карары**

16.11.2020

№ 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дурт-Мунча авыл җирлегенең Дурт-Мунча торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлегенең Дурт-Мунча авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:

- Молодежная урамындагы су үткәргечен ремонтлау, 325 м;
- территорияне чабу;
- санкцияләнмәгән чүплекләрне ликвидацияләү;
- Сабантуй үткәрү урынын төзекләндерү;
- урам яктырткычларын светодиодлы лампочкаларга алыштыру һәм ремонтлау;
- Үзәк урамындагы, Заречная урамындагы юл чокырларны ремонтлау.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Дурт-Мунча авыл җирлеге башлыгы Р.Т.Ситдиков